Түбән Тегермәнлек авыл җирлеге башкарма комитеты
Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2016 елның 15 феврале Югары Тегермәнлек авылы № 5

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Түбән Тегермәнлек авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Түбән Тегермәнлек авыл җирлеге территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру буенча административ регламентны раслау турында»2015 елның 8 сентябрендәге 15 номерлы карары үз көчен югалткан дип тану хакында

Муниципаль норматив хокукый актны законнар белән тәңгәлләштерү максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 1 өлешенең 6 пункты, 3,4 өлеше, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 15 статьясындагы 3,5 өлеше нигезендә, муниципаль норматив хокукый актны законнарга яраклаштыру максатларында, авыл җирлекләре территорияләрендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру вәкаләтләрен муниципаль районнарның җирле әһәмияттәге мәсьәләләренә кертү, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының «Түбән Тегермәнлек авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставын нигезендә карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Түбән Тегермәнлек авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Түбән Тегермәнлек авыл җирлеге территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру буенча административ регламентны раслау турында» 2015 елның 8 сентябрендәге 15 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Түбән Тегермәнлек авыл җирлегенең Югары Тегермәнлек авылы, Совет урамы, 72а йорт; Түбән Тегермәнлек авылы, Мәктәп урамы, 7а йорт адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге

“Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Түбән Тегермәнлек авыл җирлеге Башлыгы А.Н.Дмитриев